УДК 930.27:94 (470.41)

# Казанның Яңа бистә зираты ташъязма истәлекләре

*А. М. Гайнетдинов,*

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе*

# Epigraphic monuments of the Novo-Tatarskaya settlement of Kazan

*A. M. Gaynutdinov,*

*Sh. Mardzhani Institute of History, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**

Статья посвящена изучению эпиграфических памятников, сохранившихся на Новотатарском кладбище в г. Казани. Как исторический источник они играют важную роль в изучении истории, культуры и языка татарского народа, поскольку содержат информацию, которую невозможно получить из других исторических источников. Новотатарское кладбище – место упокоения многих видных, сынов и дочерей татарского народа. Здесь похоронены видные педагоги, просветители, купцы, общественные деятели, внесшие значительный вклад в развитие татарской нации. Это кладбище в разное время становилось объектом внимания исследователей. Непосредственно арабографичные памятники изучали известные ученые-археографы М. Ахметзянов, И. Хадиев и др. Но никому не удавалось изучить все памятники, имеющие историческое значение. Всего во время обследования данного некрополя автором было выявлено 1 430 памятников, с начала XIX в. по 1929 г., включительно. Анализ собранных материалов позволил установить имена 1 330 человек, похороненных в этот период. Еще около 100 памятников не удалось идентифицировать, т. к. они сохранились лишь фрагментарно. В статье анализируются и описываются некоторые эпиграфические памятники, приводятся имена мастеров-резчиков. Новизна исследования заключается в том, что эпиграфические памятники, сохранившиеся на кладбище Новотатарской слободы Казани, представляют собой большую научную ценность, и некоторые примеры этого эпиграфического наследия впервые вводятся в научный оборот.

**Abstract**

The article is devoted to the study of epigraphic monuments preserved in the Novo-Tatarskoye cemetery. As a historical source, they play an important role in the study of the history, culture, and language of the Tatar people, because they contain information that cannot be obtained from other historical sources. The Novo-Tatarskoye cemetery is the resting place of many prominent sons and daughters of the Tatar people. Prominent teachers, educators,

merchants, and public figures, who significantly contributed to the development of the Tatar nation, are buried here. This cemetery at various times was the object of regard for researchers. Arabic-script monuments were studied by famous archaeographer scholars M. Akhmetzyanov, I. Khadiev, and others. But no one managed to study all the monuments of historical significance. In total, during the examination of this necropolis, the author identified 1430 monuments dated the 19th century through 1929. The analysis of the materials collected allowed the author to identify the names of 1330 people buried during that period. About 100 more monuments could not be identified since they are preserved only piecewise. The article analyzes and describes some epigraphic monuments, and provides the names of carver masters. The novelty of the study is in the fact that the epigraphic monuments preserved in the cemetery of the Novo-Tatarskaya settlement of Kazan are of great scientific value and some examples of this epigraphic heritage are introduced into scientific discourse for the first time.

**Ключевые слова**
Татарская эпиграфика, история, надгробные камни, эпитафии, Новотатарское кладбище, памятники, историко-культурное наследие.

**Keywords**
Tatar epigraphy, history, tombstones, epitaphs, the Novo-Tatarskoye cemetery, monuments, historical and cultural heritage.

Татар халкының иң мәшһүр, төп зираты башкалабыз Казанда урнашкан. Яңа бистә зиратында милләтебез үсешенә өлеш керткән иң атаклы, абруйлы шәхесләр җирләнгәнлектән, эпиграфист галимнәр өчен андагы эпиграфик истәлекләр иң кыйммәтле өйрәнү объектлары булырга тиеш.

Хәзерге көндә каберстанның мәйданы 26,4 гектар тәшкил итә. Безнең уйлавыбызча, ул XVIII гасыр ахырында барлыкка килгән. Зиратның беренче попечителе итеп 1875 елда атаклы Казан сәүдәгәре, сәнәгатьче, җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәтҗан Ибнеямин улы Галиев (Г. Барудиның атасы) сайланган. Аннан соң 1909 елдан алып 1917 елга кадәр бу изге эшне Мөхәммәтҗанның улы Газизҗан Галиев башкарган[1].

Казан шәһәрендә борынгы эпиграфик истәлекләрнең берникадәр өлешен галимнәр өйрәнгән һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән. Яңа бистә зираты ташъязма истәлекләрен мәшһүр татар галиме М. Әхмәтҗанов 1983, 1984, 2003 елларда эпиграфик экспедицияләр вакытында өлешчә өйрәнгән һәм барлыгы 136 кабер ташының текстларының укылышларын биргән[2]. Гомумән, ул татар эпиграфикасын өйрәнүгә саллы өлеш керткән, төрле мәкаләләрендә үзе тарафыннан табылган илебезнең төрле почмакларындагы бик күп ташъязма истәлекләрне анализлаган һәм кызыклы күзәтүләр ясаган.

Тарихчылар Р. Р. Салихов һәм Р. Р. Хәйретдинов Яңа бистә зиратында җирләнгән 198 мәшһүр шәхеснең каберләрен ачыклаганнар[3]. Аларның күбесе инкыйлабтан соң вафат булган кешеләр булганлыктан, берничәсен санамаганда, кабер ташлары борынгы түгел.

Эпиграфист И. Һадиев Яңа бистә зиратындагы кайбер ташбилгеләрне өйрәнгәнлеген дә әйтеп үтәргә кирәк. Заманында ул зираттагы иң борынгы эпиграфик истәлекне ачыклаган булган: 1803 елда бакыйлыкка күчкән Мөхиббә Гайсә кызына куелган ташны[4]. Кызганычка каршы, хәзерге көндә бу истәлек сакланмаган, җимерелеп, юкка чыккан булса кирәк. И. Һадиев анда түбәндәге сүзләр язылганлыгын хәбәр иткән:

1) «Мин һиҗратин-нәбии галәйһис-сәләәм
2) меңдә ике йөз ун йитенче йылда мәрхүм
3) Мостафа хәләле Мөхиббә Гайсә кызы
4) утуз биш йәшендә маһе зөлхиҗҗәнең ун берендә
5) дарел-фәнадан дарел-бәкайә күчде нәүвәраллааһү Тәгааләә кабраһ».

Хәзерге татар теленә күчермәсе:

1) «Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе булсын) һиҗрәтеннән соң
2) мең ике йөз унҗиденче елның унберенче
3) зөлхиҗҗәсендә мәрхүм Мостафа хәләле – Мөхиббә
4) Гайсә кызы – утыз биш яшендә
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын».

Ни өчендер әлеге ташъязмада ахыргы сүз ир-атка карата кулланыла торган кушымча белән язылган. Әгәр дә бу таш дөрес укылган булса, чыннан да иң борынгы таш булып саналырга хаклы иде, тик, кызганычка каршы, бүгенге көнгә хәтле сакланмаган.

Казан шәһәренең Яңа бистә зиратының борынгы кабер ташлары әле һаман фәнни-практик яктан тулысынча өйрәнелмәгәнгә, без хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча, сакланып калган андагы бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү максатын куйдык. Без көчебездән килгәнчә, бөтен ташъязмаларны да эзләп табарга, берсен дә калдырмаска тырыштык. Карурманга охшаган зиратта эпиграфик истәлекләрне эзләү эшенең никадәр авыр һәм читен икәнлеген моны фәкать үз җилкәсендә татыган эпиграфистлар гына белә.

Яңа бистә зиратында без ачыклый алган иң борынгы кабер ташы 1813 елга карый, ул Йосыф Бикбау улына куелган. Аның текстының укылышы түбәндәгечә:

1) «Кааләллааһү Тәбәәракә вә Тәгааләә күллү мән галәйһәә
2) фәән вә йәбкаа вәҗһү Раббикә зүл-җәләәли вәл-икраам
3) күллү нәфсиң зәәикатүл-мәүүт каалән-нәбии галәйһ –
4) ис-сәләәм әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйраһ меңдә ике йөздә
5) йегерме тукызынчы йылда маһи мөхәррәмнең тукызынчы көнендә Йосыф Бикбау
6) углы илле алты йәшидә дарел-бәкайә нәкыль итде рахмәтүллааһи галәйһи рахмәтән вәәсигаһ».



*Йосыф Бикбау улына куелган кабер ташы. Казан, 2017 ел.*

*The tombstone of Yosyf Bikbavych's grave. Kazan, 2017.*

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте: Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә
2) фани, фәкать Раббыңның Олуглык һәм хөрмәт иясе булган Йөзе генә калачак.
3) Һәр җан иясе үлемне татыячак. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе булсын)
4) әйтте: «Дөнья – ахирәт басуы». [Һиҗри] мең дә ике йөз дә
5) егерме тугызынчы ел мөхәррәменең тугызынчы көнендә Йосыф Бикбау
6) улы илле алты яшендә мәңгелек дөньяга күчте. Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Әлеге кабер иясе хакында мәгълүматыбыз юк, шулай да берәр төрле бай яки сәүдәгәр булгандыр, дип фаразлыйбыз, чөнки ул заманда болай зәвыклы итеп эшләнгән ташбилгеләрне бай югары катлау вәкилләре генә куйган. Элекке заманнарда бер таш яздыру ат бәясенә тиң булган, шуңа күрә гади халыкның фәкать тамгасы төшерелгән кечкенә агач багана яки эшкәртелмәгән примитив бер таш кына куярга хәле җиткән.

Яңа бистә зиратында бик күп атаклы шәхесләргә куелган истәлекләр табылды. Мәсәлән, олуг галимнәребез Ш. Мәрҗани, Г. Баруди белән бәйле кабер ташлары, шулай ук Аитовлар, Апаковлар, Апанаевлар, Әҗемовлар, Борнаевлар, Замановлар, Субаевлар, Үтәмешевләр, Юнусовлар, Яушевлар һәм башка атаклы династияләргә нисбәт ителгән затларның ташбилгеләре сакланган.

Әйткәнебезчә, без 1929 елга хәтле вафат булган кешеләргә куелган гарәп язулы бөтен кабер ташларын исәпкә алып, барысын да өйрәндек. 1940 елдан соң куелганнарын инде тикшермәдек, чөнки, беренчедән, таш чагыштырмача яңарак булган саен аның тарихи әһәмияте кими, икенчедән, барысын да өйрәнеп бетерү мөмкин эш түгел. Яңа бистә зиратында гарәп графикасында язылган ташлар хәтта XX йөзнең икенче яртысында да очрый, хәзерге көндә дә гарәпчә язылган кабер ташы кую очраклары юк түгел. Шулай да, тарихта тирән эз калдырган берничә шәхеснең ташбилгеләрен, үткән гасырның 30-40 нчы елларында вафат булсалар да, игътибарсыз калдырмадык. Мәсәлән, шундыйлардан шагыйрь, педагог, нәшир, сәүдәгәр Ибраһим Идрис кабер ташы. Ул 1944 елның 31 мартында вафат булып, Казанның Яңа татар бистәсе зиратында җирләнгән. Өстән караганда өчпочмак формасында ясалган кабер ташында түбәндәге сүзләр язылган:

| Беренче ягы (уеп язылган): | Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе, беренче ягы: |
|---|---|
| 1. «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләә | «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә |
| 2. Милләт | «Милләт» |
| 3. көтебханәсенең | китапханәсенең |
| 4. сахиб вә нәшире | иясе һәм нәшире |
| 5. Ибраһим | Ибраһим |
| 6. бине Сөләйман | бине Сөләйман |
| 7. Идрис | Идрис |
| 8. Наласа авылында | (Наласа авылында |
| 9. туган | туган) |
| 10. 87 йәшендә вафат | 87 яшендә 1944 |
| 11. 31 март 1944 сәнәдә | елның 31 мартында вафат. |
| 12. рахимәһүллааһү Тәгааләә | Аллаһ Тәгалә аны киң |
| 13. рахмәтән вәәсигаһ». | рәхмәте белән рәхим кылсын». |

Икенче ягы (уеп язылган):
1. «Йөрдем атсыз талмады айакларым
2. эшләдем эш тынмады бармакларым
3. мәхрүм итмәңез догадан
4. дустларым тармакларым
5. Ибраһим Идрис».

Икенче ягы:
«Йөрдем атсыз – талмады аякларым,
Эшләдем эш – тынмады бармакларым.
Мәхрүм итмәгез догадан,
Дусларым, тармакларым.
Ибраһим Идрис».

Зираттагы XIX гасыр – XX гасыр башы кабер ташларын ясау өчен материал, нигездә, якын-тирәдәге карьерлардан алынган. Күп очракта, Казан арты, Кама алды, Кама аръягы, хәзерге Мари Эл Республикасының таш чыгару карьерларыннан китерелгән. Сирәк очракларда кайбер ташбилгеләрне махсус заказ белән Оренбург якларыннан, Урта Азиядән алып кайтып, каберләр өстенә урнаштырганнар.

Эш барышында без 14 ташка язу остасының исемнәрен ачыкладык: Габделбари Мөэмин улы Баруди (Казанның Дары бистәсеннән), Фәтхелкадыйр Кәлмитев, Кавамеддин Зөлфәкаров, Габделгани мулла Габдеррәкыйб улы, Фәләхеддин Кенәбаши, Шәрифҗан мөәзин, Нурулла (Нури) Бортаси, Гайсә Ганиев (Чистайдан), Гаязеддин Әхмәдҗан улы Нураев һәм Газизә Насыйбулла кызы, Мостафа Чутаи, Фәтхулла Галиәкбәр улы, Гыйнәятулла Кавали, Мостафа Коләхмәдов, Рәхимов, Әбелкасыйм, Габдрахман. Аларның кайберләре ташбилгеләрне бик зәвыклы, матур, купшы, бай орнаментлы итеп һәм каллиграфик стиль белән эшләгән, кайберләре бераз гадирәк, примитив рәвештә уеп язган, тик шулай да һәрберсенең эшләре игътибарга лаек.



*Ибраһим Идрисовка куелган кабер ташы. Казан, 2017 ел.*

*The tombstone of Ibragim Idrisov's grave. Kazan, 2017.*

Яңа бистә зираты, ниһаять, эпиграфик планда өйрәнелде, дип санарга тулы нигез бар. Хәзер инде безнең максат – барлык истәлекләрнең текстларын фәнни әйләнешкә кертү һәм эпиграфик мирасыбызны халыкка кайтару. Моның өчен тарихи кыйммәткә ия булган барлык ташбилгеләрнең текстларын чагылдырган каталог төзү өстендә эшлибез. Шунысы кызганыч, алар өйрәнелсә дә, саклау, консервация, реставрация эшләре һаман тиешле дәрәҗәдә башкарылмаган, хәтта милләтебезнең йөзек кашлары булган шәхесләрнең кабер ташлары да дәүләт тарафыннан саклауга куелмаган. Шул сәбәпле, вакыт узган саен эпиграфик истәлекләребезнең саннары кимегәннән-кими һәм без табып өйрәнгән ташларның кайберләре берничә елдан инде бөтенләй табылмаска мөмкин.

**ИСКӘРМӘЛӘР:**
1. *Липаков Е.В., Афонина Е.В.* История татарских кладбищ: Специальное издание к 1000-летию основания города Казани. – Казань. 2005. – С. 46-48.
2. *Әхмәтҗанов М.И.* Татарстандагы татар зиратлары ташбилгеләре язмалары. 1 кисәк. – Казан, 2016. – Б. 7-32.
3. *Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р.* Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков). – Казан: Изд-во «Фест», 1994. – С. 140-148.
4. *Һадиев И.* Үткәннәрнең хатирәсен ике гасыр саклый бу таш // Идел. – 1994. – № 4. – Б. 57.

**Әдәбият исемлеге**

*Әхмәтҗанов М.И.* Татарстандагы татар зиратлары ташбилгеләре язмалары. 1 кисәк. – Казан, 2016. – 92 б.

*Липаков Е.В., Афонина Е.В.* История татарских кладбищ. – Казань. 2005. – 80 с.

*Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р.* Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков). – Казан: Изд-во «Фест», 1994. – 280 с.

*Һадиев И.* Үткәннәрнең хатирәсен ике гасыр саклый бу таш // Идел. – 1994. – № 4. – Б. 56-58.

**References**

Akhmatzhanov M.I. *Tatarstandagy tatar ziratlary tashbilgelare yazmalary. 1 kisek* [Inscriptions on tombstones in Tatar cemeteries of Tatarstan. Part 1]. Kazan, 2016, 92 p.

Lipakov E.V., Afonina E.V. *Istoriya tatarskih kladbishch* [History of Tatar cemeteries]. Kazan, 2005, 80 p.

Salikhov R.R., Khayrutdinov R.R. *Respublika Tatarstan: Pamyatniki istorii i kultury tatarskogo naroda (konets XVIII – nachalo XX vekov)* [The Republic of Tatarstan: historical and cultural monuments of Tatar people (late 18th – early 20th century]. Kazan, 1994, 280 p.

Khadiev I. *Utkannarnen hatirasen ike gasyr sakliy bu tash* [This stone has been keeping memories of the past for two centuries]. IN: *Idel,* 1994, no. 4, pp. 56-58.

Фотолар авторның шәхси архивыннан.
From the author's private archive.

**Сведения об авторе**
***Гайнутдинов Айдар Марсилевич***, кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ, e-mail: aydargm@yandex.ru.

**About the author**
***Aydar M. Gaynutdinov,*** Candidate of Philological Sciences, Senior Researcher at Sh. Mardzhani Institute of History, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, e-mail: aydargm@yandex.ru.

**В редакцию статья поступила 10.01.2020, опубликована:**
*Гайнетдинов А.М.* Казанның Яңа бистә зираты ташъязма истәлекләре // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2020. – № 1. – Б. 87-92.

**Submitted on 10.01.2020, published:**
Gaynutdinov A.M. *Kazannyn Yana biste ziraty tashyazma isteleklere* [Epigraphic monuments of the Novo-Tatarskaya settlement of Kazan]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov*, 2020, no. 1, pp. 87-92.